Республика Татарстан
Совет Лешев-Тамакского
сельского поселения
Сармановского муниципального
района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

№3 14.02.2022

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне уздырганда тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) эшләүгә һәм раслауга таләпләрне раслау турында» 2017 елның 13 февралендәге 177 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне уздырганда тикшерү кәгазьләренең (контроль сораулар исемлекләренең) формаларын кушымта нигезендә расларга.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварында үз көченә керә.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы Рәисе И.З.Хабибуллин